КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 август г.Казань № 817

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 16 мартындагы 376 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 311 нче; 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче; 2019 ел, 21 сентябрь, 863 нче; 2020 ел, 3 август, 645 нче; 2021 ел, 20 сентябрь, 885 нче, 2022 ел, 29 март, 287 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ пунктлар өстәргә:

«$1^1$. Әлеге карар белән расланган Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда,

крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибе 2022 елда шулай ук эштән азат ителү куркынычы булган затлар категориясенә караган туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарга (оешма ябылуга яисә шәхси эшкуар эшчәнлеген туктатуга, оешма, шәхси эшкуар хезмәткәрләре санын яисә штатын кыскартуга һәм алар белән хезмәт килешүләрен өзүгә бәйле рәвештә эштән азат ителүгә планлаштырылган гражданнар); эш бирүче инициативасы буенча тулы булмаган эш көне (смена) һәм (яисә) тулы булмаган эш атнасы режимына эшкә күчерелгән гражданнарга; гади карар кабул иткән эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы; эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә булган, аларга карата бөлгенлек (банкротлык) турында процедуралар кулланылган; хезмәт хакы сакланмыйча ялда булучы; эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарга кагыла.

$1^{2.}$ Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең тиешле дәүләт учреждениесендә гражданны әлеге карарның $1^{1}$ пунктында күрсәтелгән категориягә кертүне раслый торган документлар һәм (яисә) белешмәләр булмаганда, мондый документлар һәм (яисә) белешмәләр гражданнан йә аның эш бирүчесеннән соратып алына.»;

әлеге карар белән расланган Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибендә:

2.9 пунктның бишенче абзацында «документлар әзерләүгә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14 пунктка «, ә күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтелми» сүзләрен өстәргә;

2.15 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин